**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5756**
**06.09.2024**

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы
социаль юнәлешле коммерцияле
булмаган оешмасы» конкурсын
үткәрү турында

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның эшчәнлеген популярлаштыру максатында һәм Башкарма комитетның 2022 елның 7 октябрендәге 5357 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын (алга таба – конкурс) 2024 елның 1 октябреннән 2024 елның 27 ноябренә кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауны 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 250 000 (ике йөз илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 6 сентябрендәге
5756 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы
социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы»
конкурсы турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурсның оештыручысы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора.

3. Конкурсны үткәрү максаты – Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалары (алга таба – СЮКБО) эшчәнлегенең ачыклыгын һәм аны популярлаштыруны тәэмин итү.

4. Конкурсның бурычлары:

1) гражданнар җәмгыятен үстерүдә СЮКБО эшчәнлеген популярлаштыру һәм аның ролен күтәрү;

2) муниципаль берәмлекнең иҗтимагый киңлегендә СЮКБОның уңай имиджын формалаштыру;

3) СЮКБО эшчәнлегенең ачыклыгын арттыру;

4) халыкның СЮКБОга ышанычын арттыру өчен шартлар тудыру;

5) халыкка социаль хезмәт күрсәтүче иң яхшы СЮКБОны ачыклау.

5. Конкурста Яр Чаллы шәһәре территориясендә 1 елдан да ким булмаган эшчәнлек алып баручы СЮКБО катнаша ала.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү вакыты һәм тәртибе

6. Конкурс 2024 елның 1 октябреннән 27 ноябренә кадәр 2 этапта үткәрелә:

1) беренче этап 2024 елның 1 октябреннән 1 ноябренә кадәр: конкурста катнашучылар тарафыннан заявкалар һәм материаллар тапшыру;

2) икенче этап 2024 елның 1 ноябренннән 27 ноябренә кадәр: конкурс комиссиясе утырышы, конкурс җиңүчеләрен билгеләү һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы.

7. Конкурста катнашу өчен СЮКБО вәкилләре 2024 елның 1 ноябренә кадәр срокта «СЮКБО КОНКУРСЫНА» билгесе белән konkurs.sonko.nch@mail.ru электрон адресы буенча һәм вәкаләтле зат имзасы һәм оешманың мөһере белән кәгазьдә Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә түбәндәге адрес буенча заявка бирәләр: Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 106 кабинет; элемтә өчен телефон: 8(960)067-39-61, 8(951)896-32-58.

8. Конкурста катнашу өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) форма буенча заявка (әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымта);

2) СЮКБО эшчәнлеген тасвирлау (әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта);

3) гамәлгә кую документларының күчермәләре (устав, ОГРН, ИНН таныклыклары);

4) җитәкченең вәкаләтләрен раслаучы документның күчермәсе;

5) 2023-2024 елларда СЮКБО эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

6) оешманың сайтына яки социаль челтәрләрдәге битенә, шул исәптән Татарстан Республикасының коммерцияле булмаган оешмалары порталына сылтамалар (2023-2024 еллардагы эшчәнлек турында басмалар белән);

7) СЮКБО эшчәнлеге турында мәгълүмати материаллар (буклетлар, мәгълүмат кәгазьләре);

8) акчалата бүләкне күчерү өчен банк реквизитлары.

9. Конкурсны үткәрү чорында мәгълүмати ачыклыкны тәэмин итү өчен документларны рәсмиләштерү буенча мәгълүмати-укыту семинары үткәрелә.

10. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Кешеләргә ярдәм» – ярдәмгә мохтаҗ категориядәге гражданнарның тормыш хәлен яхшыртуга, кешеләргә социаль ярдәм күрсәтүгә, шулай ук халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклауга, кешеләрне эзләүгә һәм халык арасында иминлек культурасын популярлаштыруга юнәлдерелгән проектлар;

2) «Мөмкинлекләр шәһәре» – талантлар ачуга һәм шәхес тәрбияләүгә, мәгарифне, ихтыярый ярдәм хәрәкәтен, фәнне, патриотизмны, мәдәни кыйммәтләрне һәм традицияләрне үстерүгә, тарихи истәлекне саклауга юнәлдерелгән проектлар;

3) «Тормыш өчен территория» – шәһәрне, шәһәр мохитен һәм социаль инфраструктураны үстерүгә, волонтерлыкка, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклауга һәм экологиягә ярдәм итүгә, хайваннарны яклауга юнәлдерелгән проектлар;

4) «Спорт шәһәре» – массакүләм спортны, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм үстерүгә, ял оештыруга, традицион гаилә кыйммәтләрен яклауга юнәлдерелгән проектлар.

## 3 бүлек. Конкурс комиссиясе

11. «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) конкурс чараларын әзерләүне һәм үткәрүне оештыру максатларында төзелә.

12. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

13. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурска тәкъдим ителгән документларны һәм материалларны карап тикшерә;

2) конкурс җиңүчеләрен билгели;

3) конкурста катнашучыларның казанышларын һәм проектларын, нәтиҗәләрен таратырга ярдәм итә.

14. Конкурс эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) грантлар бирү буенча конкурсларда актив катнашу;

2) СЮКБО эшчәнлеге хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларның актуальлеге;

3) ярдәм күрсәтелгән кешеләр саны, аларның тормышында уңай үзгәрешләр;

4) проектларның әһәмияте һәм актуальлеге;

5) үткәрелгән чаралар саны;

6) проект чараларының максатчан төркемнең тормышын яхшыртуга йогынтысы дәрәҗәсе;

7) СЮКБО эшчәнлегенең дәвамлылыгы;

8) СЮКБОның максатчан керемнәрдән файдалану тәҗрибәсе булу;

9) оешма эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгы.

15. Конкурста катнашучылар комиссия утырышында катнаша алмыйлар.

16. Комиссия утырышлары комиссия әгъзалары яртысыннан ким булмаган составта катнашканда хокуклы. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы буенча кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия әгъзаларының утырышта һәм (яки) тавыш бирүдә катнашуы мөмкин булмаган очракта, аларның фикере сораштыру ысулы белән язма рәвештә исәпкә алынырга

мөмкин.

17. Тавыш бирүгә кадәр комиссиянең барлык әгъзалары конкурста катнашучыларның документлары һәм материаллары белән танышырга тиеш.

18. Комиссиягә җитәкчелек итүне комиссия рәисе гамәлгә ашыра, ул комиссия эшен планлаштыра, комиссия утырышларын билгели һәм алып бара. Комиссия рәисе булмаган чорда утырышны аның урынбасары үткәрә.

19. Комиссия секретаре комиссия утырышларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру һәм техник эшне башкара, шул исәптән комиссиягә карап тикшерү өчен тапшырыла торган документларны (мәгълүматларны) тикшерә, шулай ук комиссия карарларын рәсмиләштерә.

20. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, алар комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм, комиссия утырышы үткәрелгән көннән башлап өч көн эчендә, рәислек итүче тарафыннан раслана.

## 4 бүлек. Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү

21. Һәрбер номинациядә җиңүчеләр билгеләнә.

Һәрбер номинациядә җиңүчеләргә дипломнар һәм 57 000 сум күләмендә акчалата бүләк бирелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Яр Чаллы шәһәренең
иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы»
конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Заявка вәкаләтле затның имзасы белән фирма бланкында электрон рәвештә һәм кәгазьдә бирелә.

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсында катнашуга
заявка

| | |
|---|---|
| СЮКБОның исеме | |
| «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә дәүләт теркәү датасы | |
| СЮКБО җитәкчесе | |
| СЮКБО җитәкчесенең элемтә мәгълүматлары (электрон почта, телефон) | |
| Конкурс номинациясе | |

Җитәкче ________________/______________

«Яр Чаллы шәһәренең
иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы»
конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы эшчәнлегенең тасвирламасы
(2023-2024 еллар өчен)

Барлык бүлекчәләр электрон рәвештә тутырыла. Әлеге бүлекнең күләме 6 биттән артмаска тиеш. Материалларны раслый торган норматив документлар, фото видео материаллар һ.б. белән тулыландырырга киңәш ителә. Кушымталарның гомуми күләме 25 биткә кадәр. Документлар вәкаләтле зат имзасы белән электрон рәвештә һәм кәгазьдә бирелә. Барлык заявкалар, өстәмә материалларны да кертеп, бердәм PDF форматта бирелергә тиеш.

| |
|---|
| 1. Сезнең оешманың тормышка ашырылган төп проектлары (аларны санагыз) |
| 2. Проектларның максаты |
| 3. Социаль хезмәт күрсәтүнең формасы (эчтәлеге) |
| 4. Максатчан аудитория |
| 5. Проектларның актуальлеге |
| 6. Сезнең өстенлек нәрсәдә? |
| 7. Социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатына мониторинг ясау механизмы нинди (нәтиҗәлелек критерийлары)? |
| 8. Грант конкурсларында катнашу |
| 9. Финанслау чыганаклары |
| 10. Эшчәнлекнең төп нәтиҗәләре (казанышлар, кыенлыклар) |
| 11. Эшчәнлекнең перспектив юнәлешләре |
| 12. Партнерлар |
| 13. Мәгълүмати ачыклык, мәгълүматлар һәм «Интернет» челтәрендәге проектларга сылтамалар |